# КАРАР

## Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына Трудовой торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2022 елның 25 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 25 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Трудовой торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, һәрби хезмәттәге,контракт буенча, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, ә 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, сугыш хәрәкәте ветераннары һәм күп балалы гаиләләр өчен түләүләр күләме гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итүе һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү белән килешәсезме:

- зияратны төзекләндерү (зиярат территориясендә яңа койма урнаштыру, материал сатып алу, булган койманы сүтү, часовня төзү, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Советская урамында суүткәргеч төзү (килешү буенча эшләр өчен түләү)

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 395 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 204 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 204 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Трудовой торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Трудовой торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, һәрби хезмәттәге,контракт буенча, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, ә 2 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, сугыш хәрәкәте ветераннары һәм күп балалы гаиләләр өчен түләүләр күләме гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итүе һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү белән килешәсезме:

-зияратны төзекләндерү (зиярат территориясендә яңа койма урнаштыру, материал сатып алу, булган койманы сүтү, часовня төзү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Советская урамында сууткәргеч төзү (килешү буенча эшләр өчен түләү)

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Майская Горка авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Майская Горка авыл җирлеге башлыгы А.П. Морозов